# КАРАР

**12 ноябрь 2025 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл жирлегенең Шура авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 12 нче ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

"Сез 2026-нче елда Яңа Кенәр авылы территориясендә яшәгән урында теркәлгән һәр олы кешедән 850 сум күләмендә үз-үзегезгә салым салырга ризалашасызмы, 1-нче төркем инвалидларын исәпкә алмаганда, гражданнар 80 яшь, инвалид балалар, сугыш ветераннары, Чернобыль атом электр станциясендә булган аварияне бетерүдә катнашучылар, түләү күләме 425 сум үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл өслегенең нигезен һәм япмасын юл-урам челтәренең туфрактан ясалган ташларыннан ясау Шура авылы: Гагарин урамы (160 м), Һ.Такташ урамы (150 м).

«ЭЙЕ» «КАРШЫ»»

Гражданнарның җыен (йомгаклау беркетмәсе) беркетмәсе нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 165 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 119 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 119 кеше тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл жирлеге Шура авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип.

2. "Сез 2026-нче елда Яңа Кенәр авылы территориясендә яшәгән урында теркәлгән һәр олы кешедән 850 сум күләмендә үз-үзегезгә салым салырга

ризалашасызмы, 1-нче төркем инвалидларын исәпкә алмаганда, гражданнар 80 яшь, инвалид балалар, сугыш ветераннары, Чернобыль атом электр станциясендә булган аварияне бетерүдә катнашучылар, түләү күләме 425 сум үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл өслегенең нигезен һәм япмасын юл-урам челтәренең туфрактан ясалган ташларыннан ясау Шура авылы: Гагарин урамы (160 м), Һ.Такташ урамы (150 м) кабул ителгән".

3. Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлегенең Шура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына Татарстан Республикасы, Арча районы, Шура авылы, Һ.Такташ урамы, 35 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә.Гайфуллин

СОВЕТ НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ